КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2019 ел, 25 апрель г.Казань № 341

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгать тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1184 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы махсус инвестиция контрактын төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгать тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1184 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы махсус инвестиция контрактын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктның «и» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан расланган халыкара конкурентлылык күрсәткече – тәэмин ителешне диверсификацияләү коэффициентын исәпләү методикасы нигезендә исәпләнгән китерүләрне диверсификацияләү коэффициенты мәгънәсе турында»;

15 пунктның «о» пунктчасында «шулай ук фараз чорының һәр елы өчен оешма хезмәткәрләренең уртача эш хакын» сүзләреннән соң «, китерүләрне диверсификация коэффициентының фараз әһәмияте» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин